## Итоговый тест в рамках промежуточной аттестации по литературному чтению на родном(татарском) языке для 3 класса

**I вариант**

**Якшәмбе саен без әтием белән базарга барабыз. Базарда һәрвакыт кеше күп. Монда яшелчә,җиләк- җимеш саталар. Тегендә чәчәкләр алырга мөмкин. Әбиләр файдалы үләннәр дә саталар. Әтием өрек, йөзем , чикләвек, алма ала. Базарда без мәтрүшкә дә алабыз. Мәтрүшкә белән чәй тәмлерәк була. Мәтрүшкә бик файдалы үлән. Базарда сыер ите, тавык ите дә саталар. Әнием сыер ите белән токмачлы аш пешерә. Мин кәбестәле аш яратам.**

**1.Базарда нәрсәләр сатмыйлар?**
А) этләр; Ә) үләннәр Б) яшелчәләр.

**2.Мин базарга кем белән барам?**
А)әни; Ә) әби Б)әти.

**3.Базарда нинди ит күп?**
А)тавык ите; Ә) сарык ите; Б)сыер ите.

**4.Әбиләр нәрсәләр саталар?**
А) җиләкләр; Ә) кыярлар Б) үләннәр.

**5.Базарга кайчан барабыз?**
А)җомга; Ә) шимбә; Б)якшәмбе.

**6.Әнием нәрсә пешерергә ярата?**
А) токмачлы аш; Ә) кәбестәле аш; Б) алма пирогы.

**7.Без базарда нәрсә алабыз ?**
А) яшелчә; Ә) җиләк- җимеш**;** Б) дару үләннәре.

**8.Нәрсә белән чәй тәмле була?**
А)лимон белән; Ә) мәтрүшкә белән; Б)конфет белән.

**9.Базарда кайчан кеше күп?**
А)якшәмбе көнне ; Ә) җомга көнне; Б)һәрвакыт.

**10.Мин нинди аш яратам.**
А) токмачлы аш; Ә) кәбестәле аш; Б)сөтле аш.

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Вс, 01 дек 2024 15:21:42 МСК
Идентификатор документа 9c934460-9133-4432-a85b-f680d956fa29

## II вариант

### Дәү әнигә күчтәнәч.

Тутырдык без тартмага
Өрек,җимеш,алманы.
Тутырдык чәй дә,конфет та
Буш урыннар калмады.

Әй, сөенер дәү әни,
Килеп төшкәч күчтәнәч.
Кызык булыр ул аңа
Алдан белеп көтмәгәч.

**(Ж.Тәрҗеманов)**

**1.Без дәү әнигә нәрсә нәрсә җибәрәбез?**
А)хат; Ә) күчтәнәч; Б)бүләк.

**2.Без кемгә күчтәнәч тутырдык?**
А) дәү әнигә; Ә) абыйга; Б)бабайга.

**3.Тартма нинди?**
А)тулы; Ә) кечкенә ; Б) буш.

**4.Тартмада нинди ашамлыклар юк?**
А)конфет һәм чәй ; Ә) бал һәм чәкчәк; Б) җимешләр.

**5.Без тартмага нинди җимеш тутырдык?**
А)өрек; Ә) йөзем; Б)каражимеш.

**6.Дәү әнигә күчтәнәчне кая тутырдык?.**
А)тартмага; Ә) сумкага; Б)әрҗәгә.

**7.Дәү әни кайчан шатлана?**
А)күчтәнәч җибәргәч; Ә) күчтәнәч алгач; Б) күчтәнәч күргәч.

**8. Дәү әни күчтәнәчне ......**
А)көтә; Ә) көтми; Б)белә.

**9.Күчтәнәч алгач, дәү әни нишләр?**
А)көләр ; Ә) кочаклар ; Б) сөенер .

**10.Дәү әнигә күчтәнәчне кем тутырды?**
А) әни белән мин; Ә) әти белән әни ; Б)без.

| Балл | 0– 4 балл | 5-6-балл | 7 - 8 балл | 9-10-балл |
|---|---|---|---|---|
| % | 40% | 50-60% | 70-80% | 90-100 % |
| Билге | “2” | “3” | “4” | “5” |

ОТПРАВИТЕЛЬ
МБОУ "Средняя Общеобразовательная Школа №130 Имени Героя Российской Федерации Майора С.А.Ашихмина"
ПОДПИСАНО
ВЛАДЕЛЕЦ СЕРТИФИКАТА
Самаркина Ирина Николаевна
ДОЛЖНОСТЬ
Директор
СЕРТИФИКАТ
00991280801FAAF15BA3173E5BBA8F1E17
ПОДПИСАН
01.12.2024 15:20:33 МСК
ПОДПИСЬ ВЕРНА